| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.12.2024 Казан ш № 799

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвешен (тикшерү сораулары исемлеген) раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 140 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвешенә (тикшерү сораулары исемлегенә) үзгәреш кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвешен (тикшерү сораулары исемлеген) раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 140 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвешенә (тикшерү сораулары исемлегенә) үзгәреш кертеп, 12 пункттагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «т/с | Зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар | Зарури таләпләрне билгеле торган норматив хокукый актларның, аларның бүленеш берәмлекләрен күрсәтеп, белешмәләре | Җаваплар | | | Искәрмә[1] |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Кулланып булмый | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Эш бирүченең хезмәткәрләр саны 35 кешедән артып китәме? | «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декаб-рендәге 565-ФЗ номерлы федераль законның 38 статьясындагы 1 өлеше (алга таба – 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль закон); «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлеше (алга таба – 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы). | | | | |
| 2. | Инвалидларны эшкә урнаш-тыру өчен бүлеп бирелгән яки булдырылган эш урыннары инвалидларны билгеләнгән квоталар санына, махсус эш урыннарының иң аз күләм-дәге санына туры киләме? | 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль законның 38 статьясындагы 1 өлеше; 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статья-сындагы 1 өлеше, 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы терри-ториясендә урнашкан оешмаларда инвалид-ларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигез-ләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш | | | | |

[1] «Искәрмә» графасы «җаваплар» графасында «кулланып булмый» дигән җавап күрсәтелгән очракта мәҗбүри тутырылырга тиеш.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәнең 3.1 пункты. | | | | |
| 3. | Эшкә урнаштырылган инвалидлар саны инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квотага туры киләме? | 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше;<br>2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 11 өлеше. | | | | |
| 4. | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары турындагы мәгълүматларны үз эченә алган локаль норматив акт кабул ителгәнме? | 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясының 2 өлешендәге 2 пункты. | | | | |
| 5. | Эш бирүче ай саен Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәте органнарына бердәм цифрлы платформада яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртип нигезендә мондый мәгълүмат урнаштырылырга мөмкин булган башка мәгълүмат ресурсларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән инвалидларны эшкә алу квотасының үтәлеше турында хәбәр итәме? | 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы федераль законның 53 статьясындагы 2 һәм 7 өлешләре;<br>2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» феде-раль законның 53 статьясындагы 1 өлешендә ка-ралган эш бирүчеләр тарафыннан дәүләт мәш-гульлек хезмәтенә мәҗбүри мәгълүмат бирү рәвешләрен раслау хакында» 2024 елның 16 ап-релендәге 195н номерлы боерыгына 7 нче рәвеш.». | | | | |

Министр Э.Ә.Зарипова